**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

07.04.2022 259-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАЖ «ЯН» шифаханә-профилакторие территориясендә су алу скважиналарын санитар саклык зоналарын билгеләү турында» 2022 елның 21 мартындагы 204-п номерлы боерыгына 1 нче кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

Боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАЖ «ЯН» шифаханә-профилакторие территориясендә су алу скважиналарын санитар саклык зоналарын билгеләү турында» 2022 елның 21 мартындагы 204-п номерлы боерыгына 1 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эчә торган һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү максатларында җир асты суларын чыгару өчен файдаланыла торган гамәлдәге скважиналарның җир асты байлыклары участогы В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАЖ «ЯН» шифаханә-профилакториеннән 1,1 км көнчыгыштарак Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында урнашкан.».

3-5 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«скважиналарның географик координатлары:

№33 скважина – 54°57'59,845" төн.киң., 52°21'54,357" көнч. оз.;

№33Р скважина – 54°58'0,226" төн.киң., 52°21'54,720" көнч. оз.».

2. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары И.И.Гобәйдуллинга йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков